**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 .11. 2023** **№ 40-6**

**»Тәтеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында " 2021 елның 29 ноябрендәге 14-5 номерлы Тәтеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакындаа**
**(Тәтеш муниципаль районы Советының 28.02.2022 № 19-3 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)**

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 08.11.2007 № 259-ФЗ Федераль законның 3.1 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 08.11.2007 № 257-ФЗ Федераль законның 13.1 статьясына, 31.07.2020 № 248-ФЗ «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Тәтеш муниципаль районы Уставы белән карар кылды:
1. Тәтеш муниципаль районы Советының 29.11.2021 № 14-5 карары белән расланган Тәтеш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәнең 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**

Кушымта

**Тәтеш муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Муниципаль контроль объектында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында торак пункт чикләрендә һәм (яки) бер үк җирле әһәмияттәге юлда утыз көн дәвамында ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, контрольдә тотылган зат йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел дәвамында даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир өсте, электр транспорты белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларының биш процентка һәм аннан да күбрәккә артуы.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, бер календарь ел эчендә юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санының алдагы календарь ел белән чагыштырганда ике һәм аннан да күбрәк тапкыр артуы.

4. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, контрольдә тотылган кешенең кулында булган яки файдаланган юл участогында календарь айда юл-транспорт һәлакәтләре санының биш процентка артуы (әмма ким дигәндә өч бозуга).

5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында яки юллар һәм урамнар киселешендә кешеләр зыян күргән яки яраланган юл шартлары белән бәйле рәвештә бер төр юл-транспорт һәлакәтенең барлыкка килүенең өч һәм аннан да күбрәк фактын ачыклау.